ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ул. Х. Такташа, 94, а/я 44,
г. Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
һӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ һӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

һ. Такташ урамы, 94 нче йорт,
Казан шәһәрә, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: gosalcogol@tatar.ru, http://gosalcogol.tatar.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

# ПРИКАЗ

22.06.2021 г. Казань № 10-07/113

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү процедурасын камилләштерү максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турын-да» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ха-кимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең адми-нистратив регламентларын әзерләү һәм раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы территориясендә ал-когольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күр-сәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) әлеге бое-рыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министр-лыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле

продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регла-ментын раслау турында» 2021 елның 20 апрелендәге боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ә.Арсланов

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең
2021 елның 22 июнендәге 10-07/113
номерлы боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә, алкоголь продукциясен ваклап сатуга һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуга лицензия бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту, аны үзгәртеп рәсмиләштерү, гамәлдә булуын яңартып җибәрү һәм гамәлдә булуын туктатуны да кертеп, алкоголь продукциясен ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны лицензияләү (алга таба – лицензия) буенча дәүләт хезмәте (алга таба – хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган шәрабны, күбекле шәрабны (шәмпан) ваклап сатуны лицензияләүдән тыш).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе (алга таба – ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе) һәм аның территориаль органнары тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм аның территориаль органнарының урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, рәсми сайтының адресы һәм электрон почта адресы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактагы эш урыннарының урнашу урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүматлар ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең http://gosalcogol.tatar.ru рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестрында» һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (алга таба – Республика порталы) урнаштырылган.

1.3.2. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен эшли. Эш сәгатьләре ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең хезмәт тәртибе нигезендә билгеләнгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы – һәр көнне, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, дүшәмбе, чәршәмбе, җомга 9:00 дән 12:00 гә кадәр; сишәмбе, пәнҗешәмбе 13:00 дән 16:00 гә кадәр.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә һәм Казан территориаль органына керү пропуск яки шәхесне таныклаучы документ буенча гамәлгә ашырыла.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең башка территориаль органнарына керү – ирекле.

1.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм аның территориаль органнарының мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында (https://gosalcogol.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

3) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яки аның территориаль органнарына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яисә аның территориаль органнарына язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә (электрон почта адресы: gosalkogol@tatar.ru);

5) КФҮ, КФҮнеңерактагы эш урыннарында.

1.3.4. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы турында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк урнашкан урын һәм аның эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Хезмәтләр күрсәтү реестры) һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (алга таба – Бердәм портал) урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат стендларында һәм ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.2, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.3.5. Бердәм порталда, Республика порталында Хезмәтләр күрсәтү реестрында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларның рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

алкогольле продукция – әзер продукция күләмендә этил спирты микъдары 0,5 проценттан артыграк булган, азык-төлек чималыннан һәм (яки) спиртлы азык-төлек продукциясеннән җитештерелгән этил спиртыннан файдаланып яки аннан файдаланмыйча җитештерелгән азык-төлек продукциясе, Россия Федера-циясе Хөкүмәте билгеләгән исемлек нигезендәге азык-төлек продукциясеннән тыш. Алкогольле продукция спиртлы эчемлекләр (шул исәптән аракы, коньяк), шәраб, җимеш шәрабе, ликерлы шәраб, күбекле шәраб (шампан шәрабе), шәраб эчемлекләре кебек төрләргә бүленә);

алкогольле продукцияне ваклап сату – алкогольле продукцияне сатып алу һәм саклауга, алга таба аны сатып алучыларга, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүне кертеп, эшмәкәрлек эшчәнлегенә бәйле булмаган шәхсән, гаиләдә, йортта куллану өчен сатып җибәрүгә бәйле эшчәнлек төре;

җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сату – алкогольле продукцияне тәэмин итү килешүе буенча сатып алу (импорттан тыш), саклау (шул исәптән ачылган куллану тарасында (төргәктә), алкогольле эчемлекләр, кулинар ризыклар, спиртлы азык-төлек продукциясе һәм башка төрле азык-төлек продукциясе әзерләү өчен куллану, ачылган куллану тарасында кулланучыга алкогольле продукцияне сатып җибәрү яки салып бирүгә бәйле, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төре;

лицензияләүче орган – ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе;

лицензия – лицензияләүче орган тарафыннан юридик затка, лицензия таләпләрен һәм шартларын мәҗбүри рәвештә үтәүне күздә тотып, алкогольле продукцияне ваклап сату яки һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкоголь продукциясе сатуга бирелгән махсус рөхсәт;

лицензия таләпләре – эшчәнлекнең лицензияләнелә торган төрен гамәлгә ашырганда лицензиат тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле Россия Федера-

циясе һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләр һәм шартлар тупланмасы;

лицензиягә дәгъва белдерүче зат – лицензияләүче органга алкогольле продукцияне ваклап сату хокукын алу өчен лицензия бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән юридик зат;

лицензиат – алкогольле продукцияне ваклап сату яки һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкоголь продукциясе сатуга лицензиясе булган юридик зат;

мөрәҗәгать итүче (лицензиягә дәгъва белдерүче зат) – лицензия бирү турында гариза белән лицензияләүче органга мөрәҗәгать иткән юридик зат;

этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аларны әйләнешкә кертү өчен бирелгән, туктатылган һәм юкка чыгарылган лицензияләрнең дәүләт җыелма реестры – бирелгән, гамәлдә булу срогы озайтылган, үзгәртеп рәсмиләштерелгән, гамәлдә булуы туктатып торылган, гамәлдә булуы яңартып җибәрелгән, гамәлдә булуы туктатылган һәм юкка чыгарылган лицензияләр турындагы белешмәләрне үз эченә алган мәгълүматлар тупланмасы;

техник хата – лицензияне рәсмиләштергәндә лицензияләүче орган тарафыннан җибәрелгән техник характердагы ялгышлык (язу, хәреф хаталары һ.б.);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән рас-ланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Респуб-ликасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган терри-ториаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел-ның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пун-кты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)). Гаризаларның формалары 5 нче кушымтада, 6 нчы кушымтада, 7 нче кушымтада, 8 нче кушымтада, 9 нчы кушымтада, 10 нчы кушымтада, 11 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы | Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү. | «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчү) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2 п., 4 п. (алга таба – 171-ФЗ номерлы Федераль закон) |
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе. | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 6 ст. 1 пункты, 18 ст. 10 п.; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын |

| | | |
|---|---|---|
| | | яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 елның 5 августындагы 391 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 1.1 п., 3.3 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | 1) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында күрсәтмә һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия;<br>2) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында күрсәтмә һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия;<br>3) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында күрсәтмә һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуга гамәлдә булу срогы озайтылган лицензия;<br>4) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында күрсәтмә һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга гамәлдәге вакыты озайтылган лицензия;<br>5) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында күрсәтмә һәм (яки) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензия;<br>6) лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү турында күрсәтмә;<br>7) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүдән баш тарту турында күрсәтмә; | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. 7, 8, 9, 11, 12, 17 пунктлары, 20 ст. 1, 2 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | 8) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүдән баш тарту турында күрсәтмә;<br>9) лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында күрсәтмә;<br>10) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында күрсәтмә;<br>11) лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрүдән баш тарту турында күрсәтмә;<br>12) лицензиат гаризасы нигезендә лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында күрсәтмә;<br>13) кире алу турында гариза нигезендә гаризаны карау процедурасын туктату турында күрсәтмә. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Лицензияне бирү, гамәлдә булу вакытын озайту, үзгәртеп рәсмиләштерү, бирү, бирүдән баш тарту, озайтудан баш тарту яки үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү гариза алынган көннән башлап 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Өстәмә экспертиза үткәрү кирәк булганда, әлеге срок аны уздыру чорына озайтыла, ләкин гаризаны карау срогын озайту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итеп, 30 календарь көненә кадәр генә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Лицензиаттан лицензиянең гамәлдә булуын туктатуга китергән шартларны бетерү турында гариза алынганнан соң 14 календарь көне эчендә лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү яки аның гамәлдә булуын яңартып җибәрүдән баш тарту һәм лицензияне юкка чыгару турында гариза белән судка мөрәҗәгать итү турында карар кабул ителә.<br>Лицензиатның гаризасы буенча лицензиянең гамәлдә булуын туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү срогы – лицензияне теркәп тапшырган гаризаны теркәгәннән соң 10 эш көненнән дә | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. 7 п.;<br><br><br><br><br>171-ФЗ номерлы Федераль законның 20 ст. 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | артмый.<br>Лицензиягә дәгъва белдерүче затка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.<br>Лицензиянең гамәлдә булуын туктатудан баш тарту яки туктату турында күрсәтмә бирү (җибәрү) күрсәтмә имзаланган вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны һәм теркәлә торган документларны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә тапшыру тәэмин ителә. Гаризаның КФҮ булу вакыты алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар яисә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар бирү процедурасын гамәлгә ашыру срогына кертелми. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул | Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен 1 нче кушымтага туры китереп документлар тапшырыла.<br>Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен 2 нче кушымтага туры китереп документлар тапшырыла.<br>Лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту өчен 3 нче кушымтага туры китереп документлар тапшырыла.<br>Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен 4 нче кушымтага туры китереп документлар тапшырыла.<br>Лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү өчен | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. 3.2, 3.2-2 п.;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | лицензиат лицензияләүче органга, нигезләү документларын теркәп, лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга сәбәпче булган шартларның бетерелүе турында гариза тапшыра.<br>Лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү турындагы гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә: оешманың исеме һәм оешу-хокук формасы, урнашу урыны, ИНН, лицензиянең реестр һәм теркәү номеры, лицензияне бирү датасы; лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән шартлар һәм күрсәтелгән шартларны бетерү ысулы.<br>Лицензиянең гамәлдә булуын туктату өчен лицензиат 11 нче кушымтага туры китереп, аның гамәлдә булуын туктату турында гариза бирә.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>1) шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан) яисә почта аша кәгазьдә яисә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми электрон почтасы аша электрон документлар рәвешендә;<br>2) күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә яки 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә.<br>Гаризаны тапшырган вакытта мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктән гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән язу бирелә;<br>3) Республика порталы аша электрон формада.<br>Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерүне ала, анда | Федераль закон);<br>«Алкогольле продукцияне ваклап сатуны хәл итүче оешмаларның түләнгән устав капиталының минималь күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының һәм карарлары нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2014 елның 15 мартындагы 161 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 1 пункты;<br>Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Устав капиталын түләүне раслаучы документлар турында» 13.12.2005 ел, № ШТ-6-07/1045 хаты |

| | | |
|---|---|---|
| | гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.<br>Гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.<br>Гариза Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган электрон формадагы документларны тапшыра.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкы ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырылган. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | 1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсендә).<br>2. Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милек объекты турында белешмәләр (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә).<br>3. Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерү (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә).<br>4. Салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе).<br>Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документ- | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. 3.2, 3.2-2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | ларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны.<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк | «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары);<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | танылканган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Гаризаның вәкаләтле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы.<br>2.Тапшырылган документларда өстәп язылган, чистартылган, сүзләре сызылган, алдан сөйләшенмәгән төзәтүләр булуы, шулай ук карандаш белән тутырылган документлар, эчтәлеген бер мәгънәдә аңлау мөмкинлеген бирми торган җитди бозык урыннары булган документлар булуы.<br>3. Гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (танылканмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру.<br>Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела. | 210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>63-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1. лицензия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) мөрәҗәгать итүченең 171-ФЗ номерлы Федераль законның 2, 8, 9, 10[1], 11, 14[1], 16, 19, 20, 25 һәм 26 статьялары нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве;<br>2) 171-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы таләпләрен бозу;<br>3) мөрәҗәгать итүчедә лицензияләүче органга лицензия бирү турында гариза алынган айның беренче көненә һәм гариза алынган көнгә түләнмәгән, лицензияләүче органның рәсми | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. 9 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгате буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен файдаланып алынган электрон документ формасында салым органы белешмәсе белән расланган салымнар, җыемнар, иминият кертемнәрен, шулай ук салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булуы;<br>4) тапшырылган документларда төгәл булмаган, ялган, шулай ук тулы булмаган мәгълүматлар булуы, әгәр тулы булмаган мәгълүмат мөрәҗәгать итүченең әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән статья кушымталары нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирмәсә яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аларны әйләнештә йөртүгә бәйле эшчәнлек төрләренең берсен гамәлгә ашыруга тиешле лицензия бирү өчен каралган документларның тулы булмаган комплекты тапшырылуы;<br>5) дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләре буенча, лицензия бирү турындагы гариза лицензияләүче органда теркәлгән көннән соңгы икенче эш көненә туры килгән датага мөрәҗәгать итүчедә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган һәм этил спиртын, алкогольлек һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнештә йөртү өлкәсендә кылынган хокук бозулар өчен билгеләнгән административ штраф булуы.<br>2. лицензияне озайтудан баш тарту өчен нигезләр:<br>1) мөрәҗәгать итүченең 171-ФЗ номерлы Федераль законның 2, 8, 9, $10^1$, 11, $14^1$, 16, 19, 20, 25 һәм 26 статьялары нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве;<br>2) 171-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы | |

| | | |
|---|---|---|
| | таләпләрен бозу;<br>3) мөрәҗәгать итүчедә лицензияләүче органга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза алынган айның беренче көненә һәм гариза алынган көнгә түләнмәгән, лицензияләүче органның рәсми мөрәҗәгате буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен файдаланып алынган электрон документ формасында салым органы белешмәсе белән расланган салымнар, җыемнар, имиият кертемнәрен, шулай ук салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булуы;<br>4) тапшырылган документларда төгәл булмаган, ялган, шулай ук тулы булмаган мәгълүматлар булуы, әгәр тулы булмаган мәгълүмат мөрәҗәгать итүченең әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән статья кушымталары нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирмәсә яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аларны әйләнештә йөртүгә бәйле эшчәнлек төрләренең берсен гамәлгә ашыруга тиешле лицензия бирү өчен каралган документларның тулы булмаган комплекты тапшырылуы;<br>5) дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләре буенча, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турындагы гариза лицензияләүче органда теркәлгән көннән соңгы икенче эш көненә туры килгән датага мөрәҗәгать итүчедә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган һәм этил спиртын, алкогольлек һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнештә йөртү өлкәсендә кылынган хокук бозулар өчен билгеләнгән административ штраф булуы.<br>3. лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | нигезләр:<br>1) мөрәҗәгать итүченең 171-ФЗ номерлы Федераль законның 2, 8, 9, $10^1$, 11, $14^1$, 16, 19, 20, 25 һәм 26 статьялары нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве;<br>2) 171-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы таләпләрен бозу;<br>3) тапшырылган документларда төгәл булмаган, ялган, шулай ук тулы булмаган мәгълүматлар булуы, әгәр тулы булмаган мәгълүмат мөрәҗәгать итүченең әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән статья кушымталары нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирмәсә яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция житештерү һәм аларны әйләнештә йөртүгә бәйле эшчәнлек төрләренең берсен гамәлгә ашыруга тиешле лицензия бирү өчен каралган документларның тулы булмаган комплекты тапшырылуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны үзгәртеп рәсмиләштерү өчен дәүләт пошлинасы алына, түбәндәге күләмнәрдә:<br>алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү (тапшыру) – лицензиянең гамәлдә булу срогының һәр елы өчен 65 000 сум;<br>җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү (тапшыру) – лицензия гамәлдә булу срогының һәр елы өчен 65 000 сум;<br>лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту – алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү өчен билгеләнгән күләмдә;<br>юридик затны үзгәртеп корганда (берләштерү, кушу | Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктындагы 94 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | рәвешендә юридик затларны үзгәртү яки үзгәртеп корудан тыш һәм үзгәртеп корылган юридик затларны дәүләт теркәвенә алу датасына һәр юридик затта эшчәнлекнең шул бер үк төрен гамәлгә ашыруга лицензиясе булган хокуклы варисы булган очрактан тыш) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – лицензиянең тиешле төрен биргән өчен билгеләнгән күләмдә;<br>берләштерү, кушу рәвешендә юридик затларны үзгәртү яки үзгәртеп корганда һәм үзгәртеп корылган юридик затларны дәүләт теркәвенә алу датасына һәр юридик затта эшчәнлекнең шул бер үк төрен гамәлгә ашыруга лицензиясе булган хокуклы варисы булган очракта – 3500 сум;<br>юридик затның исеме (үзен үзгәртмичә), лицензиядә күрсәтелгән эшчәнлек алып бару урыны яки лицензиядә күрсәтелгән башка мәгълүматлары үзгәрүгә, шулай ук лицензия югалуга бәйле рәвештә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – 3 500 сум.<br>Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту, аны үзгәртеп рәсмиләштерү өчен оешмалар тарафыннан дәүләт пошлинасы түләү өчен счет реквизитлары:<br>Исәп-хисап счеты – 03100643000000011100<br>К/с (бердәм казначылык счеты) 40102810445370000079<br>Банкның БИК – 019205400<br>Алучы зат банкы – Россия Банкының ТР Милли банкы бүлекчәсе//Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре<br>ИНН 1654025044<br>КПП 165901001<br>Алучы зат – Татарстан Республикасы буенча ФКИ (Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ш/с 04112001330)<br>Бюджет классификациясе коды: 750 1 08 07082 01 1000 110<br>ОКТМО 92701000 | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы ярдәмендә алдан тутырылган реквизитлар буенча башкарыла ала.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләгәндә мөрәҗәгать итүчегә түләү документының тутырылган яки өлешчә тутырылган, шулай ук тутырылган түләү документының күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Түләү документында исәпләмәнең уникаль идентификаторы һәм түләүченең идентификаторы күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы факты турында мөрәҗәгать итүчегә Республика порталы аша хәбәр ителә.<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүченең түләү кертүен раслый торган документлар тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат бирү, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасында булган мәгълүматлардан файдаланып гамәлгә ашырыла. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Лицензиягә дәгъва белдерүче зат (лицензиат) тарафыннан кәгазьдә гариза тапшыру, чират булган очракта – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 пункты |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк аша бирелгән гариза ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гариза күпфункцияле үзәктән алынган көнне теркәлә.<br>Республика порталына электрон формада килгән гариза (техник мөмкинлек булган очракта) билгеләнгән тәртиптә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан ул алынган көнне теркәлә, әгәр Республика порталында гаризалар автомат теркәлеп бармаса. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм аның | «Россия Федерация- |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | территориаль органнарының түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә:<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары;<br>Татарстан Республикасының дәүләт интеграцияле телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмат киоскысы белән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен | сендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;<br>880 номерлы ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| | кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;<br>хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, | Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе бинасының һәм аның территориаль органнарының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Дәүләт алкоголь инспекциясе рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары биналарын һәм бүлмәләрен инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук | 880 номерлы ТР МК карарының 2,4 п.;<br>Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки аннан файдалана алмау | инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген бирә торган башка шартлар үтәлешен тәэмин итү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары белгечләре белән хезмәттәшлеге:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда турыдан-туры-бердән дә артмый (консультацияне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары биналарының, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарның инвалидлар өчен үтемле булуы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булу күрсәткечләренә ирешү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелгәндә, консультацияләү һәм документларны кабул итү КФҮ белгече тарафыннан башкарыла. Лицензиягә дәгъва белдерүче затка лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе яки аның территориаль органнары белгечләре тарафыннан бирелә.<br>Техник мөмкинлек булган очракта, кирәкле документларны электрон рәвештә тапшыру (КФҮ электрон санлы имзасы белән имзаланган документларның скан-үрнәкләре) КФҮ мәгълүмат системасы аша башкарыла. Бу очракта кәгазьдәге документлар ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә һәм аның территориаль органнарына КФҮ белән килешүдә күрсәтелгән вакыт дәвамында җибәрелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә, аның территориаль органнарына, КФҮ (шәхсән яки телефон аша) телдән мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук gosalcogol.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан, КФҮ алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте территориаль принцип буенча, лицензиат яисә лицензиягә дәгъва белдерүче затның ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яисә юридик затны (мөрәҗәгать итүчене) дәүләт теркәвенә алу урыны буенча ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең тиешле территориаль органына мөрәҗәгать итү юлы белән күрсәтелә (16 нчы кушымта).<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлек- | Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин. | 63-ФЗ номерлы Федераль закон; 210-ФЗ номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| ләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Дәүләт хезмәте электрон формада, шул исәптән Республика порталыннан файдаланып та, күрсәтелә.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:<br>1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;<br>3) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;<br>5) дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Республика порталы аша ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерә ала.<br>Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.<br>Гаризаны электрон рәвештә формалаштырганда мөрәҗәгать итүчегә түбәндәге мөмкинлекләр тәэмин ителә: | Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;<br>гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;<br>файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән электрон формага ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон формага элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;<br>ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Республика порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон форма кырларын тутыру;<br>элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;<br>мөрәҗәгать итүченең Республика порталында элегрәк бирелгән гаризаларны карый алу мөмкинлеге.<br>Гаризаны җибәргән вакытта, мөрәҗәгать итүченең шәхесе исәпкә алу язуын активлаштырганда билгеләнгән булу шарты белән, гади электрон имза кулланыла.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Республика порталы, күпфункцияле үзәкнең элемтә үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.<br>Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.<br>Билгеле бер датага язылу вакыты әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.<br>Республика порталы аша алдан язылу өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән: | |

| | | |
|---|---|---|
| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);<br>телефон номерын;<br>электрон почта адресын (ихтыярына карап);<br>кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.<br>Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.<br>Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.<br>Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.<br>Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.<br>Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

3.1. Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән рәсми почтага gosalcogol@tatar.ru электрон документ формасында), КФҮ, Республика порталыннан алынган гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү;

4) лицензияне бирү, үзгәртеп рәсмиләштерү, яңартып җибәрү, туктату, гамәлдә булу срогын озайту турында күрсәтмә әзерләү һәм раслау;

5) лицензияне бирүдән, үзгәртеп рәсмиләштерүдән, яңартып җибәрүдән, туктатудан, озайтудан баш тарту турында күрсәтмә әзерләү һәм раслау;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

7) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче лицензияләү бүлегенә яки ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органына шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Лицензияләү бүлеге белгече яки территориаль органны лицензияләү белгеченә (алга таба – лицензияләү белгече) мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, бирелә торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен башка мәсьәләләр буенча да консультация бирә.

Лицензияләү белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү предметы буенча консультация бирә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә, мөрәҗәгать итүчегә Республика порталы, КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Мөрәҗәгать итүче КФҮгә шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында консультация алырга хокуклы.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән (мөрәҗәгатьне теркәү) көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: консультация, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны

рәсмиләштерү өлешендә, мөрәҗәгать итүчегә Республика порталы, КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге турында хәбәр итү.

3.3. Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү.

3.3.1. Лицензия алырга теләүче шәхсән, яки электрон рәвештә (электрон имза белән имзаланган (таныкланган) документлар рәвешендә) яки почта аша (теркәлгәннәр исемлеге һәм белдерү белән кыйммәтле почта юлламасы итеп) лицензия бирү турында гариза (5 нче кушымта, 6 нчы кушымта) юридик затның дәүләт теркәвенә алу урыны буенча лицензияләүче органга тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә, шул исәптән Республика порталы аша документлар тапшыра.

Лицензия бирү турындагы гаризага мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе яки ышаныч кәгазе нигезендә аның исеменнән эш итүгә вәкаләтле зат имза куя.

Документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече җавапны электрон формада алу фактын раслый, аның датасы һәм теркәү номеры күрсәтелә.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматындагы «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивына формалаштырылган рәвешендә тапшырыла.

Республика порталы аша электрон формада гариза биргән очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара::

Республика порталында авторизация уза; Республика порталында электрон гариза формасын ача; дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

документларны электрон формада яки электрон документ рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билге билгели);

тутырылган электрон гариза җибәрә (тиешле электрон гариза формасындагы төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәр ала.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә җибәрелгән гариза.

3.3.2. Лицензияләү белгече:

1) документлар документар формада килгәндә:

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булуын тикшерә;

документларны исемлеге буенча кабул итү яки кире кайтару;

кулдан тапшырылган яки почта, яисә электрон почта аша алынган гаризаны гаризаларны теркәү журналында теркәү (12 нче кушымта);

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, алынганда беркетелгән номеры турында тамгалап, документлар исемлеге күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыру (җибәрү);

2) документлар электрон формада алынган очракта, лицензияләү белгече:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон рәвешләрен өйрәнә;

документларның электрон рәвешләренең комплектлылыгын, укылышлылыгын тикшерә;

Бердәм порталга керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квали-фикацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәк-ләре тапшырылган булса);

мөрәҗәгать итүче вәкаләт биргән зат сыйфатында эш итүче мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерә;

документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, гариза һәм теркәлгән документларны терки һәм карау өчен Бүлеккә җибәрә;

документларны кабул итү датасы, алганда беркетелгән номеры турында тамгалап, гариза күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра яки почта яки электрон почта (ихтыярына карап) аша җибәрә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гариза һәм документларны, Бүлек белгече әзерләгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, теркәмичә генә кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, гариза һәм документлар электрон формада ял (бәйрәм) көнендә алынган очраклардан тыш, гариза һәм документлар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәү журналында гаризаларны теркәү язуы һәм үтәү өчен җибәрелгән документлар яки документларны кире кайтару турында хат.

3.3.3. Лицензияләү белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә;

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милек объекты турында өземтә бирү турында – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә;

Салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында белешмәләр бирү турында – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә;

эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерү бирү турында – Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсенә (техник мөмкинлек булса), җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында гариза каралган очракта.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр һәм документлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.3.4. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә; күчемсез милек объекты турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә күчемсез милек объекты турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында соралган белешмәләрнең булмавы турында белдерү; салымнар һәм җыемнар, пенялар һәм штрафлар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен бурычлар булуы яки булмавы турында белешмәләр; эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерү (техник мөмкинлек булган очракта).

3.3.5. Лицензияләү белгече, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында булган мәгълүматлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү фактын тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат алу.

3.3.6. Лицензияләү белгече дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләре буенча, лицензия бирү турындагы гариза лицензияләүче органда теркәлгән көннән соңгы икенче эш көненә туры килгән датага мөрәҗәгать итүчедә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган һәм этил спиртын, алкогольлек һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнештә

йөртү өлкәсендә кылынган хокук бозулар өчен билгеләнгән административ штраф булуын яки булмавын тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненең икенче көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: административ штраф булуы яки булмавы турында мәгълүмат алу.

3.3.7. Алынган документлар һәм белешмәләр нигезендә лицензияләү белгече:

лицензия эшен формалаштыра (аерым папканы комплектацияли);

тапшырылган документларның җитәрлек булуын, рөхсәт ителүен һәм дөреслеген тикшереп, тапшырылган документларның законнардагы таләпләргә туры килү-килмәве буенча планнан тыш документар тикшерү уздыра, шул исәптән түбәндәгеләрнең дә башкарылган булуына инана:

документлар мөһерләр белән беркетелгән, аларда якларның яки вәкаләтле вазыйфаи затларның тиешле имзалары бар;

документларның текстларында чистартылган яки өстәп язылган, сүзләре сызылган һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтүләр юк.

Планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләре буенча лицензияләү белгече документар тикшерү турында акт, электрон формадагы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә проекты рәсмиләштерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.3.3, 3.3.5 пунктларында күрсәтелгән процедуралар тәмамланганнан соң дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: формалаштырылган лицензия эше, документар тикшерү акты, электрон формадагы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә проекты.

3.3.8. Документларга өстәмә экспертиза уздыру кирәк булган очракта, лицензияләү белгече:

документларга өстәмә экспертиза билгеләү һәм гаризаны карау вакытын озайту турында хезмәт язуы әзерли;

өстәмә экспертиза үткәрү турында күрсәтмә проекты әзерли;

әзерләнгән документларны имзалау өчен лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: документларга өстәмә экспертиза билгеләү һәм гаризаны карау вакытын озайту зарурлыгы турында хезмәт язуы, күрсәтмә проекты.

3.3.9. Лицензияләүче орган җитәкчесе өстәмә экспертиза үткәрү турында карар кабул итә, документларга өстәмә экспертиза үткәрү турындагы күрсәтмәне имзалый (уңай карар кабул ителгән очракта) һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: өстәмә экспертиза үткәрү турында карар, имзаланган күрсәтмә.

3.3.10. Лицензияләү белгече ташырылган документларга өстәмә экспер-тиза үткәрү зарурлыгына бәйле рәвештә гаризаны карау срогын озайту кирәклеге турындагы күрсәтмәне мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.3.8-3.3.10 пунктларында билгеләнә торган процедуралар өстәмә экспертиза үткәрү турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документларга өстәмә экспертиза үткәрү турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән күрсәтмә.

3.3.11. Лицензияләү белгече төгәл мәгълүматлар алу максатында тиешле дәүләт органнарына рәсми мөрәҗәгатьләр юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.3.12. Алынган мәгълүматлар нигезендә лицензияләү белгече:

тапшырылган документларның алынган мәгълүматларга туры килү-килмәве буенча анализ ясый;

документларга өстәмә экспертиза үткәрә;

электрон формадагы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә проекты әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формадагы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә проекты.

3.3.13. Лицензия бирү турында гариза тапшырган мөрәҗәгать итүчегә карата яки лицензиянең гамәлдә булу вакытын үзгәртеп рәсмиләштерү яки аның гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза биргән лицензиатка карата шулай ук планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрелә. Планнан тыш күчмә тикшерүләр уздыру тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспек-циясенең 2017 елның 24 ноябрендәге 12-07/200 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентында билгеләнгән.

Процедураның нәтиҗәсе: күчмә тикшерү акты.

3.3.14. Электрон формада гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә проекты һәм тикшерү актлары нигезендә лицензияләү белгече:

гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли;

лицензия эшен формалаштырып бетерә, анда түбәндәгеләрне урнаштыра: гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә; теркәлә торган документлар һәм күчмә тикшерү уздыру турында күрсәтмә теркәлгән күчмә тикшерү уздыру турында акт; ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы буенча алынган документлар; документар тикшерү үткәрү турында күрсәтмә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләргә таянып, лицензия бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында күрсәтмә проекты әзерли;

әзерләнгән күрсәтмә проектын, лицензия эше белән бергә, лицензияләүче орган җитәкчесенә килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында җитәкчегә җибәрелгән күрсәтмә проекты.

3.3.15. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензия бирү турында күрсәтмәне яисә лицензия бирүдән баш тарту турында күрсәтмәне имзалый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында имзаланган күрсәтмә.

3.3.16. Лицензияләү белгече:

лицензиягә дәгъва белдерүче затка лицензия бирү яки, лицензия бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензия бирүдән баш тарту турында күрсәтмә бирә (почта яисә электрон почта аша җибәрә);

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына лицензия турында мәгълүматлар кертә;

дәүләт җыелма реестрына мәгълүматлар кертү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) күрсәтмә, лицензия турындагы белешмәләрне мәгълүматлар базасына кертү, белешмәләрне дәүләт җыелма реестрына кертү.

3.3.17. Лицензияләү белгече:

лицензия бирү турындагы белешмәләрне этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнешкә кертү өчен бирелгән, туктатылган һәм юкка чыгарылган лицензияләрнең дәүләт җыелма реестрына (алга таба – дәүләт җыелма реестрына) кертә (13 нче кушымта);

күрсәтмәне лицензия эше материалларына терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт җыелма реестрына кертелгән, бирелгән лицензия турында белешмәләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында мөрәҗәгать итүче дәүләт җыелма реестрыннан белешмәләр булган җавапны бердәм портал аша ала.

3.4. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү

3.4.1. Лицензиат шәхсән, яисә электрон почта аша (электрон имза белән имзаланган (расланган) документлар рәвешендә) яисә почта аша (почта аша, теркәлгәннәр исемлеге һәм белдерү белән кыйммәтле почта юлламасы) лицен-зияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта, 10 нчы кушым-та) лицензияләүче органга тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты ниге-зендә, шул исәптән Республика порталы, КФҮ аша да, документлар тапшыра.

Документларны электрон формада тапшырган очракта, лицензияләү белгече, датасын һәм теркәү номерын күрсәтеп, аларның алынуын электрон формада җавап хәбәре җибәреп раслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматында, «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивында формалаштырылган рәвештә тапшырыла.

Гаризаны Республика порталы аша электрон формада тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә җибәрелгән гариза.

Оешманы үзгәртү (кушу рәвешендә юридик затларны үзгәртеп корудан тыш һәм үзгәртелгән юридик затларны дәүләт теркәвенә алу датасына һәр катнашучы юридик затның алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиясе булган хокуклы варисы булган очрактан тыш) лицензияне үзгәртеп рәсмиләш-терү әлеге Регламентның 3.3.2 – 3.3.19 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Лицензиатның исеме үзгәргәндә (аның үзен үзгәртмичә кенә), аның урнашкан урыны яисә аерымланган бүлекчәләренең лицензиядә күрсәтелгән урыннары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган стационар сәүдә объектының аренда срогы беткәндә, сәүдә объектларын ачканда яки япканда, лицензиядә күрсәтелгән башка белешмәләр үзгәргән очракта, шулай ук лицензияне югалткан очракта да, әлеге Регламент-ның 3.4.2-3.4.11 пунктчаларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

3.4.2. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә башкарыла.

3.4.3. Лицензияләү белгече:

3.4.3.1. ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә;

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милек объекты турында өземтә бирү турында – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә;

эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерү бирү турында – Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсенә (техник мөмкинлек булса), җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза каралган очракта.

3.4.3.2. Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында булган мәгълүматлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү фактын тикшерә.

3.4.3.3. Әлеге Регламентның 3.4.3.1, 3.4.3.2 пунктларында билгеләнгән процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр; дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат алу.

3.4.3.4. Тапшырылган документларның җитәрлек күләмдә булуын, рөхсәт ителгәнлеген һәм төгәллеген билгеләүне дә кертеп, тапшырылган документларга аларның гамәлдәге законнар таләпләренә туры килүенә экспертиза уздыру әлеге Регламентның 3.3.7 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.4. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә; күчемсез милек объекты турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә күчемсез милек объекты турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында соралган белешмәләрнең булмавы турын-да белдерү; эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра

башлау турында белдерү (техник мөмкинлек булган очракта); дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат алу.

3.4.5. Лицензияләү белгече документларга экспертиза (әлеге Регламент-ның 3.3.7 п.) һәм күчмә тикшерү акты (әлеге Регламентның 3.3.13 пункты) нигезендә:

гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли;

лицензия эшен формалаштырып бетерә, анда түбәндәгеләрне урнаш-тыра: гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә; теркәлә торган документлар һәм күчмә тикшерү уздыру турында күрсәтмә теркәлгән күчмә тикшерү уздыру турында акт; ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы буенча алынган документлар; документар тикшерү үткәрү турында күрсәтмә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар;

әлеге Регламентның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты» бүлегенең 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләргә таянып, лицензияне үзгәртеп рәсми-ләштерү яисә үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында күрсәтмә проекты әзерли;

әзерләнгән күрсәтмә проектын, лицензия эше белән бергә, лицензия-ләүче орган җитәкчесенә килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү яки аны үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында күрсәтмә проекты.

3.4.6. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензияне үзгәртеп рәсмиләш-терү турында күрсәтмәне яисә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында күрсәтмәне имзалый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү яки аны үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында имзаланган күрсәтмә.

3.4.7. Лицензияләү белгече:

лицензиягә дәгъва белдерүче затка лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү яки, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында күрсәтмә бирә (почта яисә электрон почта аша җибәрә);

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына лицензия турында мәгълүматлар кертә;

дәүләт җыелма реестрына мәгълүматлар кертү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү яки аны үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) күрсәтмә, лицензия турындагы белешмәләрне мәгълүматлар базасына кертү, белешмәләрне дәүләт җыелма реестрына кертү.

3.4.10. Лицензияләү белгече:

Дәүләт җыелма реестрына үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензия турында белешмәләр кертә;

күрсәтмәне лицензия эше материалларына терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт җыелма реестрына кертелгән, үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензия турында белешмәләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында мөрәҗәгать итүче дәүләт җыелма реестрыннан белешмәләр булган җавапны бердәм портал аша ала.

3.5. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту

3.5.1. Лицензиат шәхсән, яисә электрон почта аша (электрон имза белән имзаланган (расланган) документлар рәвешендә) яисә почта аша (почта аша, теркәлгәннәр исемлеге һәм белдерү белән кыйммәтле почта юлламасы) лицен-зиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза (7 нче кушымта, 8 нче ку-шымта) лицензияләүче органга тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече, датасын һәм теркәү номерын күрсәтеп, аларның алынуын электрон формада җавап хәбәре җибәреп раслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document форма-тында сканер аша уздырылган документлар рәвешендә тапшырыла

Гаризаны Республика порталы аша электрон формада тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә җибәрелгән гариза.

3.5.2. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә башкарыла.

3.5.3. Лицензияләү белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә;

Салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында белешмәләр бирү турында – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр һәм документлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5.4. Лицензияләү белгече, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында булган мәгълүматлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү фактын тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат алу.

3.5.5. Лицензияләү белгече дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләре буенча, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турындагы гариза лицензияләүче органда теркәлгән көннән соңгы икенче эш көненә туры килгән датага мөрәҗәгать итүчедә Адми-нистратив хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган һәм этил спиртын, алкогольлек һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнештә йөртү өлкәсендә кылынган хокук бозулар өчен билгеләнгән административ штраф булуын яки булмавын тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненең икенче көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: административ штраф булуы яки булмавы турында мәгълүмат алу.

3.5.6. Тапшырылган документларның җитәрлек күләмдә булуын, рөхсәт ителгәнлеген һәм төгәллеген билгеләүне дә кертеп, тапшырылган документ-ларга аларның гамәлдәге законнар таләпләренә туры килүенә экспертиза уздыру әлеге Регламентның 3.3.7 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.7. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә; салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен салымнар һәм җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында белешмәләр.

3.5.8. Лицензияләү белгече документларга экспертиза (әлеге Регламент-ның 3.3.7 п.) һәм тикшерү акты (әлеге Регламентның 3.3.13 пункты) нигезендә:

гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли;

лицензия эшен формалаштырып бетерә, анда түбәндәгеләрне урнаштыра: гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә; теркәлә торган документлар һәм күчмә тикшерү уздыру турында күрсәтмә теркәлгән күчмә тикшерү уздыру турында акт; ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы буенча алынган документлар; документар тикшерү үткәрү турында күрсәтмә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар;

әлеге Регламентның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты» бүлегенең 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләргә таянып, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яисә гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында күрсәтмә проекты әзерли;

әзерләнгән күрсәтмә проектын, лицензия эше белән бергә, лицензияләүче орган җитәкчесенә килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач ике эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яисә озайтудан баш тарту турында күрсәтмә проекты.

3.5.9. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яки лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турындагы күрсәтмәне имзалый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган күрсәтмә.

3.5.10. Лицензияләү белгече:

лицензиягә дәгъва белдерүче затка лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында күрсәтмә бирә (почта яисә электрон почта аша җибәрә);

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына лицензия турында мәгълүматлар кертә;

дәүләт җыелма реестрына мәгълүматлар кертү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яки гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) күрсәтмә, лицензия турындагы белешмәләрне мәгълүматлар базасына кертү, белешмәләрне дәүләт җыелма реестрына кертү.

3.5.11. Лицензияләү белгече:

дәүләт җыелма реестрына лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында белешмәләр кертә;

күрсәтмәне лицензия эше материалларына терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт җыелма реестрына кертелгән, гамәлдә булу вакыты озайтылган лицензия бирү турында белешмәләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында мөрәҗәгать итүче дәүләт җыелма реестрыннан белешмәләр булган җавапны бердәм портал аша ала.

3.6. Лицензия бирү (лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризаны кире алу)

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче лицензияләүче органга шәхсән яки почта аша (теркәлгәннәрнең исемлеге һәм белдерүле кыйммәтле почта юлламасы белән), яисә электрон почта аша (лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында) гаризаны кире алу турында, шул исәптән Республика порталы аша да, ирекле рәвештә гариза бирергә хокуклы.

Гаризаны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече, датасын һәм теркәү номерын күрсәтеп, аларның алынуын электрон формада җавап хәбәре җибәреп раслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматында, «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивында формалаштырылган рәвештә тапшырыла.

Гаризаны Республика порталы аша электрон формада тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында гаризаның электрон формасын ача; дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә җибәрелгән гариза.

3.6.2. Гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы (12 нче кушымта) нигезендә башкарыла.

3.6.3. Лицензияләү белгече:

лицензияне бирү (гамәлдә булу вакытын озайту, үзгәртеп рәсмиләштерү) турында гаризаны карау процедурасын туктату турында күрсәтмә проек-ты әзерли;

күрсәтмә проектын имзалау өчен лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: күрсәтмә проекты.

3.6.4. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензия бирү (гамәлдә булу вакытын озайту, үзгәртеп рәсмиләштерү) турында гаризаны карау процедурасын туктату турындагы күрсәтмәне имзалый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган күрсәтмә.

3.6.5. Лицензияләү белгече почта яисә бирүчегә электрон почта аша мөрәҗәгать итүчегә күрсәтмә җибәрә.

лицензиатка лицензия бирү (аның гамәлдә булу вакытын озайту, аны үзгәртеп рәсмиләштерү) турында гаризаны карау процедурасын туктату турында күрсәтмә бирү (почта яисә электрон почта аша җибәрү);

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына лицензия

турында мәгълүматлар кертү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияне бирү (аның гамәлдә булу вакытын озайту, аны үзгәртеп рәсмиләштерү) турында гаризаны карау процедурасын туктату турында бирелгән (җибәрелгән) күрсәтмә.

3.6.6. Лицензияләү белгече мөрәҗәгать итүчегә лицензия бирү (аның гамәлдә булу вакытын озайту, аны үзгәртеп рәсмиләштерү) турында гариза белән бергә лицензияләүче органга тапшырылган документларны да кире кайтара. Гаризага теркәлгән исемлектә документларның мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелүе турында тамга ясала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

3.7. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү

3.7.1. Лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү өчен лицензиат лицензияләүче органга шәхсән, яисә электрон почта яки почта аша (теркәлгәннәр исемлеге һәм белдерүле кыйммәтле почта юлламасы итеп) лицензиянең гамәлдә булуын туктатуга бәйле шартларны юкка чыгаруга бәйле рәвештә, әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә нигезләү документларын теркәп, аның гамәлдә булуын яңартып җибәрү турында, шул исәптән Респуб-лика порталы аша да, гариза тапшыра.

Гаризаны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече, датасын һәм теркәү номерын күрсәтеп, аларның алынуын электрон формада җавап хәбәре җибәреп раслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматында, «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивында формалаштырылган рәвештә тапшырыла.

Гаризаны Республика порталы аша электрон формада тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында гаризаның электрон формасын ача; дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә җибәрелгән гариза.

3.7.2. Лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә башкарыла.

3.7.3. Лицензияләү белгече лицензиат тарафыннан лицензиянең гамәлдә булуын туктатуга китергән шартларны бетерү фактын раслау максатында планнан тыш тикшерү үткәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиат тарафыннан лицензиянең гамәлдә булуын туктатуга китергән шартларның бетерелү фактын раслау.

3.7.4. Тапшырылган документлар нигезендә лицензияләү белгече:

лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү яки яңартып җибәрүдән баш тарту турында күрсәтмә проекты әзерли;

күрсәтмә проектын имзалау өчен лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән, лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү яисә яңартып җибәрүдән баш тарту турында күрсәтмә проекты.

3.7.5. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрүдән баш тарту турындагы күрсәтмәне имзалый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрүдән баш тарту турында имзаланган күрсәтмә.

3.7.6. Лицензияләү белгече:

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрүдән баш тарту турында мәгълүматлар кертә;

лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрүдән баш тарту турында мәгълүматларны дәүләт җыелма реестрына кертә;

лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрүдән баш тарту турында күрсәтмә бирә (почта яисә электрон почта аша җибәрә).

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү турында мәгълүматлар ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат базасына кертелгән белешмәләр, лицензиатка бирелгән (җибәрелгән) лицензиянең гамәлдә булуын яңартып җибәрү турында күрсәтмә.

3.8. Лицензиат гаризасы нигезендә лицензиянең гамәлдә булуын туктату

3.8.1. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату лицензиатның, лиценцияне теркәп, лицензияләнгән эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруны туктату турында шәхси гаризасы (11 нче кушымта) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.2. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. Лицензияләү белгече:

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында күрсәтмә проекты әзерли;

күрсәтмә проектын имзалау өчен лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач җиде эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында күрсәтмә проекты.

3.8.4. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында күрсәтмәне имзалый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында имзаланган күрсәтмә.

3.8.5. Лицензияләү белгече ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгъ-лүмат базасына лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында мәгълүмат

кертә һәм лицензиатка лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы күрсәтмәне кулына тапшыра.

Лицензияләү белгече лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белешмәләрне ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына, Дәүләт җыелма реестрына кертә һәм ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән күрсәтмә, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белешмәләрне ТР Дәүләт алко-голь инспекциясенең мәгълүмат базасына кертү, ТР Дәүләт алкоголь инспек-циясенең рәсми сайтында урнаштыру.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату датасы булып лицензиянең гамәл-дә булуын туктату турында имзаланган күрсәтмә датасы тора.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы күрсәтмә өч эш көне эчендә, сатуны чикләү максатларында, барлык сәүдә объектларында алкоголь-ле продукциянең калган өлешен исәптән төшерү нигезе булып тора.

3.9. Дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү техник хатага бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.9.1. Лицензияләү белгече, техник хата ачыкланган очракта, доклад язуы әзерли һәм тиешле аңлатма белән аны лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрелгән доклад язуы.

3.9.2. Лицензияләүче орган җитәкчесе дәүләт җыелма реестрына үзгә-решләр кертү турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында ли-цензияләү белгеченә хәбәр итә.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү турында карар.

3.9.3. Лицензияләү белгече:

дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү турында күрсәтмә проекты әзерли;

күрсәтмә проектын имзалау өчен лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: күрсәтмә проекты.

3.9.4. Лицензияләүче орган җитәкчесе:

дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү турындагы күрсәтмәне имзалый;

күрсәтмәне лицензияләү белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесе имзалаган дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү турында күрсәтмә.

3.9.5. Лицензияләү белгече лицензиатка дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү турында күрсәтмә җибәрә.

Лицензияләү белгече:

лицензиатка дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү яки, кертүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында күрсәтмә бирә (почта яки электрон почта аша җибәрә);

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына үзгәрешләр кертә;

Дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү яки дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) күрсәтмә, мәгълүмат базасына үзгәрешләр кертү, дәүләт җыелма реестрына үзгәрешләр кертү.

3.9.6. Лицензияләү белгече:

бирелгән лицензияне алмаштыру турындагы белешмәләрне ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына кертә;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләрнең дәүләт җыелма реестрына кертелгән белешмәләр.

3.9.7. Лицензиат, лицензиядә һәм аңа кушымтада техник хата ачыкланган очракта, бирелгән лицензияне алыштыру турында лицензияләүче органга ирекле рәвештә гариза бирә.

Лицензияне алыштыру, лицензия һәм аңа кушымта бирү әлеге Регламентның 3.9.3 – 3.9.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган регламент нигезләмәләрен һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, ТР Дәүләт

алкоголь инспекциясенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр санала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү;

2) эшне алып баруны тикшерүне билгеләнгән тәртиптә үткәрү;

3) билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешенә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган мәгълүматлар, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны башкаручы вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар кулланыла.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар кичекмәстән дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы министр урынбасарына хәбәр итәләр, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләр эзлеклелегенең үтәлешен агымдагы контроль җитәкче урынбасары, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыручы бүлек башлыгы тарафыннан башкарыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

Контроль тикшерүләр планлы булырга мөмкин (ТР Дәүләт алкоголь инс-пекциясенең еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате каралырга мөмкин.

4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү барышында алар тарафыннан кабул ителә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплылыгы.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылык тота.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка дәүләт хезмәткәрләре законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан да, тикшереп тору тәртибенә һәм рәвешләренә карата таләпләрне характерлый торган нигезләмәләр

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлегенең ачыклыгы ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, оешмалар, Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарларына, аларның эшчәнлегенә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр тәртиптә (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вазыйфаи заты һәм (яки) аның территориаль органнары һәм (яки) аның территориаль органы карарларына һәм гамәл-ләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә кабул ителгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла. КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә, КФҮ карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата КФҮ гамәлгә куючы затка бирелә.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән, түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең үтенечен теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшырылуы яисә гамәлгә ашырылуы каралмаган документлар яисә мәгълүмат тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тартылганда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республи-касы законнары һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федера-циясе, Татарстан Республикасы, муниципаль норматив хокукый актларда каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вазый-фаи заты яки ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы ва-зыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә үзләре җибәргән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең тиешле срогы бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бирү срогы яки тәртибе бозылганда;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда;

10) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәм (яки) документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы яки дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар таләп ителгәндә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлеше-нең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтыннан (http://https://gosalcogol.tatarstan.ru) Республика порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүче шәхси кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, КФҮ рәсми сайты, Республика порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүче шәхси кабул итү вакытында да кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәткән органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон

почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) белән килешмәгән дәлилләре.

5.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә кергән шикаять, алынган көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән унбиш эш көне, ә шикаять белдерүдән баш тарткан очракта, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең, КФҮ мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яки җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән сроклары бозылган очракта, – теркәлгән көннән алып биш эш көн эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республи-касы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында.

5.7. Әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килгән көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм, мөрәҗәгать итүче теләге буенча, электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе, КФҮ тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсыз-лыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында башкарылырга тиешле эшләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозу составы яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.11. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе, шулай ук аның вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә эзлекле гамәлләр тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында хәбәр итү;

2) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсми-ләштерү, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продук-цияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә документлар белән гариза җибәрү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында хәбәр итү.

Мөрәҗәгать итүче КФҮләргә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәс-миләштерү, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле про-дукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ сайтыннан http://mfc16.tatarstan.ru/ ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләү.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, ышанычлы зат аша яисә электрон формада алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәс-миләштерү, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү буенча дәү-ләт хезмәте күрсәтү турында КФҮ читтәге эш урыны аша язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

6.3.2. КФҮнең гаризалар кабул итүче белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Документлар пакетын формалаштыру

6.4.1. КФҮ белгече КФҮнең эш регламенты нигезендә:

документлар пакетын формалаштыра һәм аны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә КФҮнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә җибәрелгән документлар.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

## Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен документлар исемлеге

Лицензия алу өчен лицензиягә дәгъва белдерүче зат лицензияләүче органга түбәндәге документларны тапшыра:

1. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында гариза. (5 кушымта).

2. Мөрәҗәгать итүченең билгеләнгән күләмдә (җәмәгать туклануы һәм кулланучылар кооперациясеннән тыш) кимендә 300 мең сум күләмендә устав капиталы (устав фонды) булуын раслаучы документлар:

устав капиталын (устав фондын) акчалата түләгәндә – банкның устав капиталын түләүгә исәп-хисап счетына акча күчерүне раслаучы белешмәсе, җитәкче һәм баш хисапчысы имзалаган банк белешмәсе, шулай ук беренчел түләү документлары күчермәләре;

устав капиталын (устав фондын) акчалата түләгәндә – акционер (катна-шучы) милкенә хокукын раслаучы документ күчермәсе, бәяләү объектларын бәяләү турында хисап һәм мөлкәтне кабул итү-тапшыру актын теркәп;

устав капиталын (устав фондын) үз акчалары (аерым алганда, бүленмәгән табыш) хисабына арттырганда – оешманың устав капиталын (устав фондын) үзгәртү турында тиешле карар теркәлгән идарә органы утырышы беркетмәсенең күчермәсе, капиталлаштыру турында карар кабул ителгән оешма балансын һәм устав капиталын (устав фонды) арттыруны чагылдыручы соңгы хисап датасына булган балансны теркәп.

3. Мөрәҗәгать итүче милегендә, хуҗалыгында, оператив идарәсендә яки срогы килешүдә билгеләнгән һәм бер һәм аннан күбрәк ел тәшкил иткән аренда шартларында стационар сәүдә объектларының һәм склад бүлмәләренең булуын раслый торган документларның күчермәләре. Әгәр үзләренә карата хокуклар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән, күчемсез милек объектларына карый торган әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмаса, мондый документлар (анда булган белешмәләр) лицензияләүче органның рәсми мөрәҗәгате буенча күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

## Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен документлар исемлеге

Лицензия алу өчен лицензия алырга теләүче оешма лицензияләүче органга түбәндәге документларны тапшыра:

1. Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында гариза. (6 нчы кушымта).

2. Мөрәҗәгать итүче милегендә, аның хуҗалыгында, оператив идарәсендә яки килешүдә срогы билгеләнеп, бер һәм аннан күбрәк ел тәшкил иткән аренда шартларында җәмәгать туклануының стационар объекты булуын (бюджет учреждениеләреннән тыш) раслый торган документларның күчермәләре («Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясе куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 6 пунктындагы 3 пунктчасында, 10 пунктының тугызынчы абзацында каралган очраклардан тыш). Бюджет учреждениесе булып торучы мөрәҗәгать итүче тарафыннан оператив идарәдә, түләүсез нигездә файдалануда һәм килешүдә срогы билгеләнеп, бер һәм аннан күбрәк ел тәшкил иткән аренда шартларында җәмәгать туклануының стационар объекты булуын раслый торган доку-ментлар тапшырыла («Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясе куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 6 пунктындагы 3 пунктчасында, 10 пунктының унберенче абзацында каралган очраклардан тыш). Әлеге пунктта күрсәтелгән күчемсез милек объектларына (түләүсез файдалануда җәмәгать туклануы объекты булуын раслаучы документлардан тыш) карый торган, үзләренә кагылышлы хокук Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмаган очракта, мондый документлар (аларда булган белешмәләр) лицензияләүче орган белән үзара хезмәттәшлек тәрти-бендә федераль башкарма хакимият органының күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәка-ләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан рәсми мөрәҗәгать буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә тапшырыла;

2.1. Мөрәҗәгать итүче милегендә, аның хуҗалыгында, оператив идарәсендә яки аренда шартларында җәмәгать туклануы буенча хезмәт күрсәтү өчен файдалануга планлаштырыла торган җәмәгать туклануы объекты булуын раслый торган документның күчермәсе («Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясе куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 6 пунктының 2 пунктчасында каралган очракта лицензия бирелгәндә). Бюджет учреждениесе булып торучы мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүчедә оператив идарәдә, түләүсез файдалануда яки аренда шартларында җәмәгать туклануы буенча хезмәт күрсәтү өчен фай-даланугa планлаштырыла торган җәмәгать

тыкланыуы объекты булуын раслый торган документлар тапшырыла («Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясе куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статья-сының 6 пунктының 2 пунктчасында каралган очракта лицензия бирелгәндә);

2.2. Мөрәҗәгать итүче милегендә, аның хуҗалыгында, оператив идарәсендә яки аренда шартларында вагон-ресторан (вагон-кафе, вагон-буфет, вагон-бар(, вагон судносы, һава судносы булганлыгын һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең аларда җәмәгать тукланыуы буенча хезмәт күрсәтү хокукына ия булуын раслый торган документларның күчермәләре (гомуми файдаланудагы шәһәрара һәм халыкара элемтәсендәге тимер юл һәм су транспортында, шулай ук гомуми файдалану транспортына карамый торган тимер юл һәм су транс-портында хезмәтләр күрсәтелгәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны күздә тоткан лицензия бирелгән очракта, аерымланган бүлекчә урнашкан урын урынына вагон-ресторанның (вагон-кафеның, вагон-буфетның, вагон-бар-ның) су судносының тиешле транспорт чаралары өчен билгеләнгән тәртиптә аларга бирелгән теркәлү белешмәләре күрсәтелә).

3. Җәмәгать тукланыуы хезмәтләре күрсәтә башлау турында белдерү күчермәсе. Әгәр әлеге документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыл-маса, техник мөмкинлек булганда, әлеге документ лицензияләүче органның ведомствоара таләбе буенча башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы тарафыннан тапшырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать тукланыуы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту өчен документлар исемлеге

1. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза (7 нче кушымта) яки җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза (8 нче кушымта).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен документлар исемлеге

1. Юридик зат үзгәртеп корылган очракта, оешма лицензия алу өчен лицензияләүче органга Административ регламентка 1 нче кушымта нигезендә билгеләнгән тәртиптә документлар тапшыра.

Юридик затларны кушу, берләштерү яки үзгәртеп кору рәвешендә үзгәр-теп корган очракта, лицензияләүче органга әлеге Административ регламент-ның 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләнгән тәртиптәге документ-лар тапшырыла, 1 нче кушымтаның 3 пунктында каралган документлардан тыш.

2. Оешма атамасы үзгәртелгән очракта (үзе үзгәртеп корылмаганда) яки аның урнашкан урыны үзгәртелгәндә, лицензиат тиешле үзгәрешләр гамәлгә кую документларында теркәлгән көннән башлап утыз көнлек срокта лицензияләүче органга түбәндәгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) оешма – лицензиат яки нотариаль рәвештә таныкланган үзгәрешләр кертүне раслаучы гамәлгә кую документларының күчермәләре (күчермәләре нотариус тарафыннан расланмаган очракта, оригиналларын күрсәтеп);

в) элек бирелгән лицензиянең оригиналы.

3. Аерымланган бүлекчәләренең (шул исәптән өстәмә сәүдә объект-ларын ачу) урнашкан, лицензиядә күрсәтелгән урыннары үзгәртелгән очракта, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган стационар сәүдә объектының аренда срогы тәмамланган очракта, лицензияне үзгәртеп кору зарурлыгын китереп чыгарган шартлар барлыкка килгән көннән башлап утыз көнлек чорда лицензиат лицензияләүче органга түбәндәге документларны тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсми-ләштерүгә гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) мөрәҗәгать итүче милегендә, хуҗалыгында, оператив идарәсендә яки срогы килешүдә билгеләнгән һәм бер яки аннан күбрәк ел тәшкил иткән аренда шартларында стационар сәүдә объектлары һәм склад бүлмәләре булуын раслый торган, лицензия алырга теләүче оешма тарафыннан яки нотариаль яктан таныкланган документларның күчермәләре (күчермәләре нотариаль таныкланмаган булса, оригиналларын күрсәтеп).

в) җәмәгать туклануы буенча хезмәт күрсәтә башлау турында белдерү күчермәсе (җәмәгать туклануы буенча хезмәт күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштергән очракта)

в) элек бирелгән лицензиянең оригиналы.

4. Лицензиядә күрсәтелә торган сәүдә объекты ябылуга бәйле мәгълүматларны үзгәрткәндә лицензиат лицензияләүче органга түбәндәгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать тукланусы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) элек бирелгән лицензиянең оригиналлары һәм ябыла торган сәүдә объектына карата кушымта.

5. Лицензия югалган очракта, лицензиат лицензияләүче органга түбәндәнгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать тукланусы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) лицензияне югалтуны раслый торган документлар (лицензияне югалту сәбәпләре турында аңлатма һәм массакүләм мәгълүмат чараларында лицензияне югалту факты турында мәгълүматларны бастырып чыгару).

6. Лицензиядә күрсәтелгән бүтән мәгълүматларны үзгәрткәндә, лицензиат лицензияләүче органга түбәндәгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать тукланусы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) мондый үзгәрешләрне китереп чыгарган конкрет юридик фактлар турында белешмәләрне раслый торган документлар, шулай ук аларга бәйле өстәмә материаллар;

в) элек бирелгән лицензиянең оригиналы.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәт-ләре күрсәтелгәндә алкогольле про-дукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Җитәкчегә

______________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе территориаль органы)

**ГАРИЗА**

______________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия вакытын озайтуыгыз турында үтенәм

____________________ ____________________ *еллык* срок *белән*
(лицензиянең сериясе, реестр номеры)

Оешманың урнашу урыны ______________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН ____________________ КПП ____________________
(оешманың теркәлү урыны буенча)

ОГРН ______________________________

Исәп-хисап счеты ______________________________

______________________________________________
(банк исеме)

Телефон ____________________ электрон почта ____________________

Оешма җитәкчесенең имзасы ______________________________
(Ф.И.А.)

Мөһер урыны «_____» __________ 20__ ел.

| № т/с | Сәүдә объектының төре һәм атамасы | Сәүдә объекты урнашкан урын адресы[1] | Сәүдә объектының кадастр номеры | Сәүдә объектының мәйданы | Сәүдә объектының КПП | Сәүдә объектының эш режимы | Стациона сәүдә объе координат лары күрсәткечл |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[1] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст.; 2015, № 18, 2707 ст.; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Җитәкчегә

___________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
территориаль органы)

_________________________

# ГАРИЗА

_______________________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия вакытын озайтуыгыз турында үтенәм

______________________________ ______________________________ *еллык* срок *белән*
(лицензиянең сериясе, реестр номеры)

Оешманың урнашу урыны___________________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН ________________________________ КПП __________________________
(оешманың теркәлү урыны буенча)

ОГРН ________________________________________________________________

Исәп-хисап счеты ______________________________________________________

_____________________________________________________________________
(банк исеме)

Телефон ____________________ электрон почта ____________________________

Оешма җитәкчесенең имзасы _____________________________
(Ф.И.А.)

Мөһер урыны «_____» __________ 20__ ел.

| № т/с | Җәмәгать туклануы объектының төре һәм атамасы | Җәмәгать туклануы объекты урнашкан урын адресы[2] | Җәмәгать туклануы объектының кадастр номеры | Җәмәгать туклануы объектының мәйданы | Җәмәгать туклануы объектының КПП | Җәмәгать туклануы объектының эш режимы | Стациона[illegible] җәмәгат[illegible] туклану[illegible] объекть[illegible] координат[illegible] лары күрсәткеч[illegible] |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

___________________

[2] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст.; 2015, № 18, 2707 ст.; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
7 нче кушымта

Җитәкчегә

___________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
территориаль органы)

_________________________

# ГАРИЗА

______________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия вакытын озайтуыгыз турында үтенәм
_____________________________ ________________ *еллык* срок *белән*
(лицензиянең сериясе, реестр номеры)

Оешманың урнашу урыны_____________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН ________________________ КПП ______________________________
(оешманың теркәлү урыны буенча)

ОГРН__________________________________________________________

Исәп-хисап счеты ___________________________________________

______________________________________________________________
(банк исеме)

Телефон _________________ электрон почта __________________________

Оешма җитәкчесенең имзасы ______________________________________
(Ф.И.А.)

Мөһер урыны «_____» ___________ 20__ ел.

| № т/с | Сәүдә объектының төре һәм атамасы | Сәүдә объекты урнашкан урын адресы[3] | Сәүдә объектының кадастр номеры | Сәүдә объектының мәйданы | Сәүдә объектының КПП | Сәүдә объектының эш режимы | Стацион сәүдә объ координа лары күрсәткеч |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

---

[3] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст.; 2015, № 18, 2707 ст.; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

Җитәкчегә

___________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
территориаль органы)

___________________________

# ГАРИЗА

_______________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия вакытын озайтуыгыз турында үтенәм

______________________________ ________________ *еллык* срок *белән*
(лицензиянең сериясе, реестр номеры)

Оешманың урнашу урыны _________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН ______________________________ КПП ______________________
(оешманың теркәлү урыны буенча)

ОГРН ___________________________________________________

Исәп-хисап счеты _______________________________________

_______________________________________________________________
(банк исеме)

Телефон __________________ электрон почта _____________________

Оешма җитәкчесенең имзасы ___________________________
(Ф.И.А.)

Мөһер урыны «_____» __________ 20__ ел.

| № т/с | Җәмәгать туклануы объектының төре һәм атамасы | Җәмәгать туклануы объекты урнашкан урын адресы[4] | Җәмәгать туклануы объектының кадастр номеры | Җәмәгать туклануы объектының мәйданы | Җәмәгать туклануы объектының КПП | Җәмәгать туклануы объектының эш режимы | Стациона җәмәгат туклану объекты координат лары күрсәткеч |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[4] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст.; 2015, № 18, 2707 ст.; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Җитәкчегә

______________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
территориаль органы)

____________________

## ГАРИЗА

______________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

оешма урнашкан урын ______________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН _______________ ОГРН ______________________

алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең үзгәртеп рәсмиләштерүегез хакында үтенәм
№__________________ сериясе_________ реестр номеры __________

__________ башлап__________ кадәр гамәлдә булу срогы белән

*чөнки* ______________________________________
(лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү сәбәбе күрсәтелә)

______________________________________________

______________________________________________

Элемтә өчен телефон _______________

Оешма җитәкчесенең имзасы ______________________
(Ф.И.А.)

Мөһер урыны «_____» __________ 20__ ел.

| №<br>т/с | Сәүдә объектының төре һәм атамасы | Сәүдә объекты урнашкан урын адресы[5] | Объектның кадастр номеры | Сәүдә объектының мәйданы | Сәүдә объектының КПП | Сәүдә объектының эш режимы | Стацион[...] сәүдә объ[...] координа[...] лары күрсәткеч[...] |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

---

[1] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст.; 2015, № 18, 2707 ст.; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
10 нчы кушымта

Җитәкчегә

___________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
территориаль органы)

_________________________

# ГАРИЗА

_______________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

оешма урнашкан урын ____________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН ______________________________ ОГРН ____________________________________

җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүегез турында үтенәм

№___________________ сериясе_________ реестр номеры __________

__________ башлап__________ кадәр гамәлдә булу срогы белән

*чөнки* ________________________________________________________________
(лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү сәбәбе күрсәтелә)

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

Элемтә өчен телефон __________________

Оешма җитәкчесенең имзасы ___________________________________________________
(Ф.И.А.)

Мөһер урыны «_____» __________ 20__ ел.

| № т/с | Җәмәгать туклануы объектының төре һәм атамасы | Җәмәгать туклануы объекты урнашкан урын адресы[6] | Җәмәгать туклануы объектының кадастр номеры | Җәмәгать туклануы объектының мәйданы | Җәмәгать туклануы объектының КПП | Җәмәгать туклануы объектының эш режимы | Стациона җәмәгат туклану объекть координат лары күрсәткеч |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[6] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст.; 2015, № 18, 2707 ст.; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
11 нче кушымта

Җитәкчегә

______________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе
территориаль органы)

___________________________

# ГАРИЗА

______________________________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

оешма урнашкан урын ____________________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН _____________________________ ОГРН __________________________________________

алкогольле продукцияне ваклап сатуга (җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга) лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктатуыгыз турында үтенәм
№____________________ сериясе_________ реестр номеры ___________

__________ башлап__________ кадәр гамәлдә булу срогы белән

Элемтә өчен телефон ___________________

Оешма җитәкчесенең имзасы ___________________________________________
(Ф.И.А.)

Мөһер урыны «_____» ___________ 20__ ел.

| № п/п | Җәмәгать туклануы объектының/сәүдә объектының тибы һәм атамасы | Җәмәгать туклануы объектының/сәүдә объектының урнашкан урыны адресы | Җәмәгать туклануы объектының/сәүдә объектының КПП |
|---|---|---|---|

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать тукланучы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

**Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм (яки) аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе**

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе | (8 843) 2789200 | cla@tatalc.ru |
| ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары | (8 843) 2789278 | Rustem.Arslanov@tatalc.ru |
| Лиөензияләштеру бүлеге җитәкчесе | (8 843) 2789199 | Huzin.Ildar @tatalc.ru |
| | | |

**ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары**

| Территориаль орган атамасы | Телефон | Адрес | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Яр чаллы территориаль органы | (8 8552) 715222, 714722 | 432800, Яр Чаллы ш., Корчагин ур., 10/34 йорт | alc21@chelny.tatalc.r |
| Түбән Кама территориаль органы | (8 8555) 366376, 366385 | 423570, Түбән Кама ш., Бызов ур., 20а йорты | alc61@nizn.tatalc.ru |
| Әлмәт территориаль органы | (8 8553) 336706, 336682, | 423461, Әлмәт ш., Шевченко ур., 88 йорт, литер А | alc71@almet.tatalc.ru |
| Зеленодольск территориаль органы | (8 271) 58515, 58672 | 422520, Зеленодольск ш., Засорин ур., 9 йорт | alc81@zeldol.tatalc.r |
| Арча территориаль органы | (8 266) 32879, 32269 | 422010, Арча ш., Банковская ур., 2а йорт | alc41@arsk.tatalc.ru |
| Чистай территориаль органы | (8 242) 51550, 51019 | 422950, Чистай ш., Бебель ур., 121 Д йорт | alc51@chist.tatalc.ru |

**ТР Министрлар Кабинеты Аппараты**

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш башкару бүлеге | (8 843) 2647774 | prav@tatar.ru |